ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК РАЙОНЫ
НОРЛАТ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
«09» октябрь 2025 ел

КАРАР
№ 23

Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 16 июнендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составындагы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Башкарма комитетының Резерв фонды турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составында Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Башкарма комитетының Резерв фонды акчаларын булдыру, тоту тәртибен, алардан файдалану турында хисаплылыкны билгеләү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 16 июнендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составындагы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Башкарма комитетының Резерв фонды турында нигезләмәгә үзгәрешләрне кертергә:

4.3 пункт. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2. «4.3. Бер тапкыр бирелә торган матди ярдәмне түләү гражданнарга күчемсез милек табигый бәла-казалардан һәм янгыннан тулысынча яисә өлешчә югалганда бирелә. Түләү күчемсез мөлкәт милекчесенә яисә күчемсез мөлкәт урнашкан җир кишәрлеге милекчесенә бирелә.

Берничә милекче булганда, түләү милекчеләрнең берсенә бирелә.».

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 16 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында(http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук торак пунктның мәгълүмати стендларында: Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Норлат авылы, М.Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Заволжье» ЦКС бинасы), Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (администрациясе бинасы) урнаштырырга.

Глава
Нурлатского сельского поселения И.М.Саттаров